| СОВЕТ<br>КУГУШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КҮГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**16 январь 2023 ел** Күгеш авылы **№ 112**

2023 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Күгеш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, «Күгеш авыл җирлеге» Зеленодольск муниципаль районы Татарстан Республикасы Уставына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. 2023 елда яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары белән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Күгеш авыл җирлеге органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелмәвен билгеләргә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) "Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Күгеш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Күгеш авылы, Мәктәп яны урамы, 1 йорт (администрация бинасы), Күгеш авылы, Мәктәп яны урамы, 1а йорт (СДК бинасы) урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Күгеш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Күгеш авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе:** **А. А. Гатауллин**